

**Ни өчен йоклар алдыннан балага әкият уку бик мөһим?**

Моның берничә сәбәбе бар:

**1.** Йоклар алдыннан балага әкият уку – үзеңнең аны яратуыңны белгертү. Сабыйга әкият уку, аның күңелен юату, аңын үстерү генә түгел – аны ничек нык яратуыгызны күрсәтү.Һәр кич саен әкият укыйсың икән, бала үзен яратуларын, аны кайгыртуларын белеп тора. Бернинди мультфильм да, ата-ананың ягымлы тавышын, күңел җылысын бирә алмый. Психологлар әйткәнчә, төнгә әкият уку бала өчен бик көчле рухи ярдәм ул. Укуны мультфильм белән алыштыру ул – кеше фантазиясенең әзер нәтиҗәсе. Ә китап, әкият балага үз дөньясын ачарга, фантазиясен эшкә җигәргә булыша.

**2**. Балага төнгә әкият укып, без аны тормышка өйрәтәбез.Әкиятләр сабыйга тормыш тәҗрибәсенә өйрәнергә, үз дөньясын ачарга ярдәм итә. Әкиятләр балага көчле, хәйләкәр, җитез, игелекле, яхшы күңелле булып үсәргә булыша. Димәк, тормышта үз урынын табарга ярдәм итә. Бигрәк тә баланың яшәү рәвешенә туры килерлек халык әкиятләрен укырга кирәк.

**3.** Балага китап укып аның сөйләм телен үстерәбез һәм хәтерен яхшыртырга булышабыз. 3 яшьтә, әгәр әти-әни бала белән шөгыльләнгән булса, аның сүз запасы мең яки аннан да артык булырга тиеш. Шуның өчен бу аралыкта сабыйга төнгә генә түгел, күбрәк тә укырга кирәк. Кабатлаулар булган әкиятләр баланың хәтерен яхшырта. Мондый әкиятләрне ике, өч тапкыр укып, сабыйга кабатлатырга була.

**4.**Әлбәттә, сабыйларның китаптагы рәсемнәргә карап йокысы качарга мөмкин. Бу проблемадан чыгу ысулы бик гади. Бүлмәдә утны сүндереп, баланы кочакка аласыз да, әкият уйлап чыгара башлыйсыз. Әлеге әкияткә балага кызык булган хәлләрне кертергә, ул яраткан уенчыкларны өстәргә була. Кызыксынып тыңлап, тәмләп, изрәп йоклап китәр нәниегез.

Бактың исә, әкият укуның файдасы баланы тизрәк йокыга талдыруда түгел икән.Баланың нерв системасы, сәламәтлеге, үсеше өчен файдалы әкиятләр. Алар баланың күз алдына китерү, уйлап чыгару сәләтен камилләштерә. Әкият тыңлаганда ул серле болын, куркак куян, нәни принцессаның нинди булуын күз алдына китерә. Бу баланың иҗади сәләтен үстерә, дип ассызыклый белгечләр.

Әкиятләр баланың сөйләмен дә яхшыртырга сәләтле. Әни кеше әкият укыганда, бала аның тавышын, сүзләр әйтелешен истә калдыра. Логопедлар, мәсәлән, өлкәнрәк балаларны әкият уйлап чыгарырга этәрергә киңәш итә. Бу шулай ук тел ачылышын, авазлар әйтелешен яхшырту өчен дә кирәк. Әни белән бала арасындагы мөнәсәбәтләр яхшыра. Нәниләр йоклар алдыннан әти-әниләре белән вакыт уздырырга ярата, бу алар өчен үзенә күрә бер ритуал, тынычлану чарасы. Күңелле әкиятләр тыңлаган балаларга куркыныч төш күрү куркынычы бермә-бер кими дип белдерә белгечләр.